КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 декабрь г.Казань № 1213

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 137 нче; 2018 ел, 4 сентябрь, 746 нчы; 2018 ел, 3 ноябрь, 979 нчы; 2018 ел, 21 декабрь, 1200 нче; 2018 ел, 28 декабрь, 1252 нче; 2019 ел, 12 февраль, 98 нче; 2019 ел, 24 май, 438 нче; 2019 ел, 9 июль, 559 нчы; 2019 ел, 18 сентябрь, 849 нчы; 2019 ел, 16 декабрь, 1151 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2020» саннарын «2022» саннарына алыштырырга;

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2019 елда кулланучылар кооперациясе оешмаларына ГЛОНАСС күзәтү системасы җайланмасын сатып алуга һәм аны күчмә сәүдә итүне гамәлгә ашыра торган махсус автотранспортка монтажлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2019 елда юридик затларга сөт җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен.»;

әлеге карарга 2019 елда кулланучылар кооперациясе оешмаларына ГЛОНАСС күзәтү системасы җайланмасын сатып алуга һәм аны күчмә сәүдә итүне гамәлгә ашыра торган махсус автотранспортка монтажлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен һәм 2019 елда юридик затларга сөт җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин